**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЧУЛПАНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЧУЛПАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
27 гыйнвар 2026 ел

Чулпан ав.

**КАРАР**
№ 12

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлегендә җирләү хезмәтләрен күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук 2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен карарның 1нче кушымтасы һәм 2нче кушымтасы нигезендә 9678 сум 63 тиен күләмендә билгеләргә һәм 2026 елның 01 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Чулпан авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — В.П. Варламова

Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге башкарма комитетының 2026 елның 27  гыйнварындагы 12 номерлы карарына 1нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең иң чик күләме.

| № | Хезмәтләр исеме | Хезмәт бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 3 228,91 |
| 3. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1 862,83 |
| 4. | Җирләү  хезмәте (кабер казу һәм  җирләү ) | 4 586,89 |
| | Барлыгы | **9 678,63** |

Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге башкарма комитетының 2026 елның 27 гыйнварындагы 12 номерлы карарына 2нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең иң чик күләме

| № | Хезмәтләр исеме | Хезмәт бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Мәетне кәфенләү (төрү) | 1 490, 27 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1 738,64 |
| 4. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1 862,83 |
| 5. | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 4 586,89 |
| | Барлыгы | **9 678,63** |